**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

06.02.2019 99-п

Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Әлеге боерыкка кушымтада бирелгән Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

5. Дәүләт экология экспертизасы бүлеге башлыгы О.В.Манидичевага әлеге Регламентны «Татарстан Республикасы Рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Дәүләт экология экспертизасы бүлегенә (О.В.Манидичева) Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянып эш итәргә, эшләрнең Регламентка туры китереп башкарылуын тәэмин итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) шушы боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 19 октябрендәге 1123-п номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

6. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2019 елның 6 февралендәге 99-п номерлы боерыгы белән расланды

Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: төбәк дәрәҗәсендәге объектларның дәүләт экология экспертизасы (алга таба – дәүләт экология экспертизасы) өчен материаллар тапшыручы физик затлар, юридик затлар, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре, җирле үзидарә органнары.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Павлюхин ур., 75.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән алып 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән алып 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Министрлыкның эш көннәрендә.

Җәмәгать транспортында «Павлюхин» тукталышына кадәр килергә кирәк:

№ 2, 4, 5, 12, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77 автобуслар;

троллейбуслар: №№ 6, 8, 12;

метро «Сукно бистәсе» станциясенә кадәр.

Керү шәхесне таныклый торган документ буенча.

1.4. Министрлыкның дәүләт экология экспертизасы бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: (843) 267-68-31.

Электрон почта адресы: Olga.Manidicheva@tatar.ru.

1.5. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайты адресы (алга таба, тиешенчә – Министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре): http://eco.tatarstan.ru, электрон почта адресы: eco@tatar.ru.

1.6. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Министрлык бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүматлар Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлык бүлмәләрендә урнаштырылган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.8. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Конституциясе (Российская газета, 1993, 25 декабрь, № 237, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 16 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 17, 1462 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 174-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4556 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон (Российская газета, 2002, 12 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, 8 апрель, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – РФ Президентының 601 номерлы Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Министрлар Советы – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт экология экспертизасы турында нигезләмә раслау турында» 1993 елның 22 сентябрендәге 942 номерлы карары (Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыентыгы, 1993, № 39, 3621 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт экология экспертизасын уздыру тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 1996 елның 11 июнендәге 698 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 698 номерлы карары)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, № 40, 4648 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелешен, үзгәртеп корылышын, капиталь ремонтын махсус сакланучы табигать территорияләре җирләрендә гамәлгә ашыру күздә тотылган объектларның проект документациясен дәүләт экспертизасын һәм дәүләт экология экспертизасын уздыру өчен тапшыру кагыйдәләрен раслау турында» 2008 елның 7 ноябрендәге 822 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 822 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 46, 5344 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында» 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 22, 3169 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләрен һәм (яки) муниципаль хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм бүтән документларны электрон документлар формасында рәсмиләштерү һәм тапшыру тәртибе турында» 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 29, 4479 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне алу өчен мөрәҗәгать иткәндә кулланылуы рөхсәт ителә торган электрон имза төрләре турында» 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 27, 3744 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары вазыйфаи затларының, шулай ук «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясенең һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне тапшыру һәм аларны карау тәртибе турында» 2012 елның 16 августындагы 840 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 35, 4829 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр алу өчен мөрәҗәгать иткәндә көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны куллану кагыйдәләрен раслау турында һәм Административ регламентларны эшләү һәм раслау кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында» 2012 елның 25 августындагы 852 номерлы карары (Российская газета, 2012, 31 август, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигать ресурслары министрлыгының «Хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне экологик нигезләү буенча күрсәтмәләр» раслау турында» 1995 елның 29 декабрендәге 539 номерлы боерыгы (Экологический вестник Москвы, 1996);

Россия Федерациясе Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча дәүләт комитетының «Россия Федерациясендә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә көтелгән йогынтысын бәяләү турында нигезләмә раслау турында» 2000 елның 16 маендагы 372 номерлы боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2000, № 31);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Дәүләт экология экспертизасының штаттан тыш экспертлары хезмәте өчен түләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 23 сентябрендәге 404 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының 404 номерлы боерыгы)(Российская газета, 2014, 9 апрель);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Дәүләт экология экспертизасын уздырган өчен чыгымнар сметасын билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 12 маендагы 205 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының 205 номерлы боерыгы)(Российская газета, 2014, 4 июль);

Татарстан Республикасы Экология кодексы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.9. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

административ регламент – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедураларының һәм административ гамәлләренең срокларын һәм эзлеклелеген, аның структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары арасында үзара хезмәттәшлек итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хакимияте башкарма органының физик яки юридик затлар белән, бүтән дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен билгели торган норматив хокукый акт;

дәүләт хезмәте – федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының, җирле үзидарә

органының функцияләрен тормышка ашыру эшчәнлеге, ул дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чигендә мөрәҗәгать итүчеләрнең гарызнамәләре буенча гамәлгә ашырыла;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтү органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле гарызнамә белән яки 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән гарызнамә белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»

экологик экспертиза – экологик экспертиза объектын тормышка ашыруга бәйле рәвештә күтелгән хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне нигезләүче документларның һәм (яки) документациянең, мондый эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмый калу максатларында, техник регламентларда һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән экологик таләпләргә туры килүен билгеләү;

мөрәҗәгать итүчеләр (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) – физик затлар, юридик затлар, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр, җирле үзидарә органнары (аларның вәкаләтле вәкилләре);

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә аңлашыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаның киңәш ителгән формасы әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләп билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм уздыру | 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы;<br>Нигезләмәнең 3.3.6 пункты |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | 1. Министрлык боерыгы белән расланган уңай дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен бирү.<br>2. Министрлык боерыгы белән расланган тискәре дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен бирү.<br>3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү | 174-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясы;<br>РФ Хөкүмәтенең 698 номерлы карары |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге | 1. Дәүләт экология экспертизасын уздыру срогы ике айдан артып китәргә тиеш түгел һәм мөрәҗәгать итүченең гаризасы нигезендә бер айга озынайтылырга мөмкин, әгәр федераль законда башкача каралмаса.<br>2. Дәүләт экология экспертизасын уздыру срогының башлануы 174-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясының 3 пункты нигезендә билгеләнә. | 174-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы<br>РФ Хөкүмәтенең 698 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | 3. Министрлык боерыгы белән расланган дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе мөрәҗәгать итүчегә аны раслаган көннән соң өч эш көне эчендә җибәрелә.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында баш тарту турында хат җибәрү – гаризаны теркәгән вакыттан башлап, шулай ук әлеге Регламентның 2.9 п. билгеләнгән срок тәмамланган датадан башлап 7 эш көне.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган | |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясында күрсәтелгән объектларга дәүләт экология экспертизасын, шул исәптән кабат, уздыру өчен, 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының $4^1$ пунктчасында күрсәтелгән объектлардан тыш, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:<br>а) дәүләт экология экспертизасы объектының аталышы турындагы мәгълүматны; мөрәҗәгать итүчегә дәүләт экология экспертизасын уздырган өчен түләү буенча счет әзерләү өчен кирәкле реквизитларны (салым түләүченең идентификация номерын (алга таба – ИНН), банк идентификация кодын (алга таба – БИК), исәпкә кую сәбәбенең кодын (алга таба – КПП), предприятиеләрнең һәм оешмаларның гомумроссия классификаторы кодын (алга таба – ОКПО), исәп-хисап счетын, корреспондент счетын (алга таба – к/счет); әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә дәүләт экология экспертизасына | 174-ФЗ номерлы федераль законның 12, 14 статьялары |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырыла торган материалларга тәфсилле тасвирламаны үз эченә алган гариза;<br>б) 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының 4[1] пунктчасында күрсәтелгән объектлардан тыш, 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы нигезендә дәүләт экология экспертизасына тиешле, билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән күләмдәге һәм дәүләт экология экспертизасына тиешле хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү материалларын үз эченә алган документация.<br>2. 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының 4[1] пунктчасында күрсәтелгән объектларга дәүләт экология экспертизасын, шул исәптән кабат, уздыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:<br>а) дәүләт экология экспертизасына тиешле объектның аталышы турында мәгълүматны; мөрәҗәгать итүчегә дәүләт экология экспертизасын уздыру буенча түләүгә счет әзерләү өчен кирәкле реквизитларны (ИНН, БИК, КПП, ОКПО, исәп-хисап счеты, к/счет); әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә дәүләт экология экспертизасына тапшырыла торган материалларның тәфсилле тасфирламасын үз эченә алган гариза;<br>б) дәүләт экология экспертизасына тиешле һәм төзелешен, үзгәртеп корылышын махсус сакланучы табигать территорияләре чикләрендә гамәлгә ашыру күздә тотыла торган объектларның тиешле махсус | |

| | | |
|---|---|---|
| | сакланучы табигать территориясенә йогынтысын бәяләү материалларын үз эченә алган документация, – 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының 4[1] пунктчасында күрсәтелгән объектларга дәүләт экология экспертизасы уздырылганда;<br>Дәүләт экология экспертизасына тиешле документация ике нөсхәдә, гариза һәм башка материаллар берәр нөсхәдә тапшырыла<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка (КФҮ, КФҮ читтән торып эшләү урынына) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән органнар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | 1. 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясында күрсәтелгән объектларга дәүләт экология экспертизасын, шул исәптән кабат, уздыру өчен, 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының 4[1] пунктчасында күрсәтелгән объектлардан тыш, Министрлык тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документлар алына:<br>а) уңай бәяләмәләр һәм (яки) дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алына торган килештерү документлары;<br>б) дәүләт экология экспертизасы объекты буенча федераль башкарма хакимият органнары бәяләмәләре, – аны күрсәтелгән органнар караган очракта, һәм, уздырылган очракта, иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәләре;<br>в) гражданнар һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) белән дәүләт экология экспертизасы объекты турында җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган фикер алышуларның материаллары.<br>Югарыда күрсәтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган, шулай ук бүтән документларны, шулай ук кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче | 174-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 2 һәм 4 пунктлары;<br>РФ Хөкүмәтенең 698 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында «а»-«г» пунктчаларында санап үтелгән очраклардан тыш.<br>2. 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының 4[1] пунктчасында күрсәтелгән объектларга дәүләт экология экспертизасын, шул исәптән кабат, уздыру өчен ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында Министрлык тарафыннан түбәндәге документлар алына:<br>а) уздырылган очракта, иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәләре;<br>б) гражданнар һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) белән дәүләт экология экспертизасы объекты турында җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган фикер алышуларның материаллары.<br>Мөрәҗәгать итүче югарыда күрсәтелгән документларны мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда аталган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| килештерү таләп итеlә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган җыелмасы тапшырылганда.<br>2. Документларның мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү хокукын раслаучы вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Баш тарту нигезләре:<br>1. 174-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең 822 номерлы карарында билгеләнгән материалларны тапшыру тәртибе бозылу.<br>2. Документация төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экологик экспертиза объекты булып тормаганда.<br>3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан элегрәк тапшырылган материалларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве турында хәбәр алынган көннән башлап 30 календарь көне узгач дәүләт экология | 174-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы;<br>РФ Хөкүмәтенең 698 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | экспертизасын оештыру һәм уздыру өчен кирәкле материалларның тапшырылмавы.<br>4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт экология экспертизасына түләү зарурилыгы турында хәбәр алынган көннән башлап 30 календарь көне узгач дәүләт экология экспертизасын уздырганга түләгәнлекне раслаучы документның булмавы.<br>5. Дәүләт экология экспертизасын уздыру барышында өстәмә эшләп бетерелергә тиешлеге ачыкланган материалларны кайтару турында мөрәҗәгать итүче гаризасы.<br>6. Дәүләт экология экспертизасын уздырмыйча документацияне кайтару турында мөрәҗәгать итүче гаризасы. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте аның өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан ук тулы күләмендә түләү шарты белән күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бүлек әзерләгән счетта һәм дәүләт экология экспертизасын уздырган өчен чыгымнар сметасында күрсәтелгән күләмдәге акча чараларын күчерү юлы белән, налсыз исәп-хисап ясап гамәлгә ашырыла. Акча күчерү өчен реквизитлар:<br>Алучы: ТР БУЕНЧА РФ ФМ ФКИ (ТР ЭКОЛОГИЯ МИНИСТРЛЫГЫ)<br>ИНН 1659036508<br>КПП 165901001<br>Р/с 40101810800000010001<br>Казан ш. Россия Банкы ГРКЦ | 174-ФЗ номерлы федераль закон;<br>РФ Табигать министрлыгының 205 номерлы боерыгы;<br>РФ Табигать министрлыгының 404 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | БИК 049205001<br>ОКТМО 92701000 (Казан)<br>Түләүнең билгеләнеше:<br>КБК – 701 115 07020 01 0000 140 – Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан оештырыла һәм уздырыла торган дәүләт экология экспертизасына тиешле документация тапшыручы тарафыннан кертелә торган, дәүләт экология экспертизасын үткәргән өчен чыгымнар сметасына туры китереп исәпләнгән җыемнар.<br>НДС салынмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең хакын билгеләү 174-ФЗ номерлы федераль законның 28 статьясы нигезендә, РФ Табигать министрлыгының 205 номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт экология экспертизасын уздыруга чыгымнар сметасын билгеләү тәртибенә һәм РФ Табигать министрлыгының 404 номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт экология экспертизасының шаттан тыш экспертлары хезмәте өчен түләү тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | 601 номерлы РФ Президенты указы |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Гариза һәм документация килгән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү турында визуаль, текстлы | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| һәм мультимедияле мәгълүматлар урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәләрен гариза белән документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырганда мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында алу мөмкинлеге (гариза белән документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеген тормышка ашыргач); | Тәртипнең 2.4 пунктының «п» пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| технологияләреннән файдаланып | хезмәт күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>әлеге Регламентны дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бозуларга карата прецендентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы (прецендентларның, шикаятьләрнең Министрлыкның һәм Министрлыктагы территориаль идарәләрнең дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми санына нисбәте);<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча); | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша җибәргәндә:<br>1. әгәр дә гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми;<br>2. әгәр дә гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – бер мәртәбәдән артык түгел.<br>Мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://www.eco.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештә гаризаны, алга таба документларның төп нөсхәләрен | |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләре | тапшыру юлы белән,  Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеге бар | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Төбәк әһәмиятендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү (алга таба – дәүләт экология экспертизасы) түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү;

3) дәүләт экология экспертизасын оештыру;

4) дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм уздыру турында боерык әзерләү һәм чыгару;

5) дәүләт экология экспертизасын үткәрү;

6) дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен раслау турында боерык әзерләү һәм чыгару;

7) расланган дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен бирү.

8) дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны аша күрсәтү.

9) техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, почта аша, телефоннан, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләрдә консультацияләү, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

3.3. Документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә вәкиле аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча

Министрлыкка Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1 пунктчасына ярашлы рәвештә материаллар теркәп, эчтәлеге әлеге Административ регламент таләпләренә җавап бирә торган гариза тапшыра. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны шулай ук «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы яки Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә дә бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләре (зарурлык булганда) билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән булырга тиеш.

Төзелешен, үзгәртеп корылышын махсус саклануча табигать территорияләре чикләрендә гамәлгә ашыру күздә тотылган объектларның проект документациясенә дәүләт экология экспертизасын уздыру өчен әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2 пунктчасында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан РФ Хөкүмәтенең 822 номерлы карары белән расланган Төзелешен, үзгәртеп корылышын махсус саклануча табигать территорияләре чикләрендә гамәлгә ашыру күздә тотылган объектларның проект документациясен дәүләт экспертизасын һәм дәүләт экология экспертизасын уздыру өчен тапшыру кагыйдәләрендә каралган тәртиптә тапшырыла.

3.3.2. Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итә һәм терки;

документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавына гариза белән документларны тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече катнашында гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдә шушы Регламентның 2.8 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр барлыгы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән документларны почта аша җибәргәндә, Бүлек белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, гаризаны һәм теркәлгән документларны «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында (алга таба – Электрон документ әйләнеше) терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм Министрга җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Министр, алга таба Министрның беренче урынбасары, Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә башлыгы) эзлекле/параллель рәвештә гаризаны карыйлар һәм карау өчен дәүләт экология экспертизасы бүлеге башлыгына (алга таба – Бүлек башлыгы) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.2. Бүлек башлыгы дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы башкаручыны билгели.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган гариза һәм документлар.

3.4. Дәүләт экология экспертизасын оештыру.

3.4.1. Җаваплы башкаручы, теркәлгән документларны алгач, түбәндәге оештыру чараларын гамәлгә ашыра:

дәүләт экология экспертизасына материаллар тапшыру тәртибенең ярашлы булуын тикшерә;

документацияне төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасы объектлары исемлегенә ярашлы булуын билгеләү өчен тикшерә;

документларның комплектлылыгын, шул исәптән документация составында хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү материалларының булуын тикшерә;

ведомствоара хезмәттәшлек системасы кысаларында тиешле дәүләт органнарыннан әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны сората (әгәр алар мөрәҗәгать итүченең үз ихтыяры белән тапшырылмаган булса).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: анализланган һәм ведомствоара хезмәттәшлек системасы кысаларында тиешле дәүләт органнарына җибәрелгән гарызнамәләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән, 3.4.1 пунктта күрсәтелгән гарызнамә нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки аларны бирүдән баш тарту турында хәбәр.

3.4.3. Җаваплы башкаручы 2.9 п. 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр булганда, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр проектын әзерли һәм алга таба эзлекле рәвештә килештерүгә һәм имза кую өчен Бүлек башлыгына, Идарә башлыгына, Министрның беренче урынбасарына, Министрга җибәрә.

Министр, алар башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә, дәүләт корпорацияләре һәм холдинглары җитәкчеләренә җибәрелгән очракта, хәбәрләргә кул куя. Бүтән очракларда хәбәргә Министрның беренче урынбасары кул куя.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура 3.4.1 п. күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эзлекле рәвештә килештерүгә һәм кул куюга җибәрелгән Министрлык хәбәре проекты.

3.4.4. Бүлек башлыгы, Идарә башлыгы, Министрның беренче урынбасары, Министр Министрлык хәбәре проектын килештерә/имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган Министрлык хәбәре.

3.4.5. Җаваплы башкаручы, материалларның комплектлы булмавы, шул исәптән хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү материалларының, дәүләт экология экспертизасы турында гражданнар һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) тарафыннан җирле үзидарә органнары оештырган фикер алышу материалларының булмавы ачыкланганда, хәбәр алынган көннән башлап 30 календарь көне эчендә материалларны комплектлап бетерү зарурлыгы турында хәбәр проектын әзерли һәм аны эзлекле рәвештә килештерүгә һәм кул кую өчен Бүлек башлыгына, Идарә башлыгына, Министрның беренче урынбасарына, Министрга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эзлекле рәвештә килештерүгә һәм кул куюга җибәрелгән Министрлык хәбәре проекты.

3.4.6. Бүлек башлыгы, Идарә башлыгы, Министрның беренче урынбасары, Министр Министрлык хәбәре проектын килештерә/имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.5 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: 30 календарь көне эчендә материалларны комплектлап бетерү зарурлыгы турында имзаланган Министрлык хәбәре.

3.4.7. Җаваплы башкаручы, 2.9 п. 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, 3.4.3-3.4.4 п. билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра.

3.4.8. Җаваплы башкаручы, 2.9 п. 1-3 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр булмаганда, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт экология экспертизасын уздыруга чыгымнар сметасын әзерли;

материалларның комплектлы булуы һәм 30 календарь көне эчендә дәүләт экология экспертизасын уздыру өчен түләү зарурлыгы турында мөрәҗәгать итүче адресына хәбәр әзерли.

Дәүләт экология экспертизасы уздыруга чыгымнар сметасы нигезендә Министрлыкның финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан түләү счеты һәм дәүләт экология экспертизасын уздырган өчен җыем түләү буенча банк реквизитлары рәсмиләштерелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эзлекле/параллель рәвештә килештерүгә һәм кул кую өчен Бүлек башлыгына, Идарә башлыгына, финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгына, Министрның беренче урынбасарына, Министрга җибәрелгән Министрлыктан хәбәр проекты.

3.4.9. Бүлек башлыгы, Идарә башлыгы, финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы, Министрның беренче урынбасары, Министр Министрлыктан хәбәр проектын килештерә/имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.8 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: материалларның комплектлы булуы һәм, сметаны һәм түләү счетын теркәп, 30 календарь көне эчендә дәүләт экология экспертизасын уздыру өчен түләү зарурлыгы турында имзаланган Министрлык хәбәре.

3.4.10. Җаваплы башкаручы, 2.9 п. 4 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, 3.4.3-3.4.4 п. билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра.

3.5. Дәүләт экология экспертизасын уздыру турында боерык әзерләү һәм чыгару.

3.5.1. Дәүләт экология экспертизасын уздырганга түләгәнлекне раслаучы документ Министрлыкка килгән очракта, җаваплы башкаручы, ул шулай ук эксперт комиссиясенең җаваплы сәркатибе дә булып тора, дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм уздыру турында эксперт комиссиясе составын (җитәкче, җаваплы сәркатип һәм эксперт комиссиясе әгъзалары), дәүләт экология экспертизасын уздыру срогын, дәүләт экология экспертизасы уздыру йөкләмәсен билгели торган боерык проектын әзерли.

Идарә башлыгы, Бүлек башлыгы, җаваплы сәркатип җитәкче кандидатуралары буенча тәкъдимнәр, ә аннан соң җитәкче катнашында эксперт комиссиясе әгъзалары кандидатуралары буенча, шулай ук дәүләт экспертизасын уздыру сроклары буенча тәкъдимнәр әзерли.

Эксперт комиссиясе әгъзаларының саны так һәм, җитәкче белән җаваплы сәркатиптән тыш, кимендә өч кешедән торырга тиеш. Эксперт комиссиясе әгъзалары Министрлыкның штатлы хезмәткәрләре һәм төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасы уздырылганда җәлеп итү өчен штаттан тыш экспертлар арасыннан билгеләнә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар 13 эш көненән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла, ә 174-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының $4^1$ пунктында күрсәтелгән объектларга карата – дәүләт экология экспертизасын уздыруга түләгәнлекне раслаучы документ килгән вакыттан башлап 1 эш көне узганчы.

Процедураның нәтиҗәсе: эзлекле/параллель рәвештә килештерүгә һәм кул кую өчен Бүлек башлыгына, Идарә башлыгына, хокукый тәэминат бүлеге башлыгына, финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгына, Министрның беренче урынбасарына, Министрга җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.5.2. Бүлек башлыгы, Идарә башлыгы, хокукый тәэминат бүлеге башлыгы, финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы, Министрның беренче урынбасары, Министр Министрлык боерыгы проектын раслый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган Министрлык боерыгы.

3.6. Дәүләт экология экспертизасын уздыру.

3.6.1. Җаваплы сәркатип дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм уздыру турында боерык раслау нәтиҗәләре буенча эксперт комиссиясе эше оештыра.

Эксперт комиссиясе эше оештыру утырышын уздырудан башланып китә, анда эксперт комиссиясенең җитәкчесе, җаваплы сәркатип, эксперт комиссиясе әгъзалары, мөрәҗәгать итүче яки аның вәкилләре, шулай ук, зарурлык булганда, бүтән мәнфәгатьле якларның вәкилләре катнаша.

Эксперт комиссиясенең оештыру утырышы дәүләт экспертизасын уздыру турында боерык чыгарылган көннән башлап 5 эш көненнән артмаган срокта уздырыла. Җаваплы сәркатип почта аша юллау, гомуми файдаланудагы мәгълүмат системаларыннан файдаланып җибәрелгән телефонограмма яки хәбәр итү юлы белән мөрәҗәгать итүчегә

эксперт комиссиясенең оештыру утырышын уздыру датасы һәм урыны турында хәбәр итә. Бүтән мәнфәгатьле якларның вәкилләренә (Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар) эксперт комиссиясенең оештыру утырышын уздыру датасы һәм урыны турында билгеләнгән тәртиптә утырышта катнашу турында язмача гарызнамә булган очракта хәбәр ителә.

Оештыру утырышы барышында:

җаваплы сәркатип дәүләт экспертизасын оештыру һәм уздыру турында боерык хакында хәбәр итә;

эксперт комиссиясе җитәкчесе дәүләт экспертизасын уздыру тәртибе турында мәгълүмат җиткерә;

мөрәҗәгать итүче яки аның вәкилләре булачак эшчәнлек холкы турында доклад ясый;

эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм эксперт комиссиясе әгъзалары (Министрлыкның штатлы хезмәткәрләреннән тыш) тарафыннан документларны карау, эксперт бәяләмәләре әзерләү буенча түләүле эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турында шартнамәләр имзалана;

эксперт комиссиясе, эксперт төркемнәре (оештырылган очракта) һәм экспертлар эшенең календарь планы тәгаенләштерелә;

төркемле (эксперт төркемнәре булганда) һәм хосусый эксперт бәяләмәләрен әзерләү сроклары билгеләнә;

эксперт комиссиясе бәяләмәсе проектын әзерләү срогы билгеләнә;

дәүләт экспертизасы объекты булып торучы документлар эксперт комиссиясе әгъзаларына тапшырыла.

Төрле яклап һәм объектив бәяләү максатында дәүләт экология экспертизасы объекты турында өстәмә мәгълүмат алу өчен, зарурлык булган очракта, дәүләт экология экспертизасының эксперт комиссиясе әгъзалары гаризалары нигезендә җаваплы сәркатип тарафыннан мөрәҗәгать итүче адресына тиешле хәбәр җибәрелә.

Дәүләт экология экспертизасы объекты турында өстәмә мәгълүмат тапшыру зарурлыгы турында хәбәр проекты җаваплы сәркатип тарафыннан дәүләт экология экспертизасының эксперт комиссиясе әгъзаларыннан тиешле гаризалар алынган көннән башлап 3 эш көненнән артмаган срокта әзерләнә, килештерү өчен бүлек башлыгына, идарә башлыгына һәм имзалау өчен министрның беренче урынбасарына тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүчедән алынган өстәмә материаллар гаризаны теркәү тәртибендә теркәүгә алына һәм эксперт комиссиясе эшендә куллану өчен җаваплы сәркатипкә тапшырыла. Мөрәҗәгать итүче өстәмә материалларны тапшырмаган очракта, дәүләт экология экспертизасы объекты булып торучы документация экспертлар тарафыннан беренчел күләмендә карала.

Зарурлык булганда, дәүләт экология экспертизасы объекты турында өстәмә мәгълүмат алу өчен, эксперт комиссиясе әгъзаларының булачак эшчәнлек урынына баруы оештырылырга мөмкин.

Эксперт комиссиясе эше барышында:

хосусый һәм төркемле (эксперт төркемнәре булганда) эксперт бәяләмәләре әзерләнә, алар эксперт комиссиясенең җаваплы сәркатибенә тапшырыла;

эксперт комиссиясенең утырышлары, шул исәптән, 174-ФЗ номерлы федераль законның 26 статьясы күздә тоткан хокукларны тормышка ашыру максатларында, мөрәҗәгать итүче һәм/яки аның вәкилләре катнашында, уздырыла

эксперт комиссиясе утырышларында хосусый һәм төркемле (эксперт төркемнәре

булганда) эксперт бәяләмәләре карала;

эксперт комиссиясенең җитәкчесе һәм җаваплы сәркатибе тарафыннан хосусый һәм төркемле эксперт бәяләмәләре нигезендә эксперт комиссиясе бәяләмәсе проекты төзелә.

Эксперт комиссиясе утырышлары эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм җаваплы сәркатибе тарафыннан имзалан торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

Эксперт комиссиясенең мөрәҗәгать итүче һәм/яки аның вәкилләре, шулай ук бүтән мәнфәгатьле якларның вәкилләре (Россия Федерациясе субъекты органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар) катнашырга мөмкин булган ахыргы утырышында:

эксперт комиссиясе бәяләмәсе проекты турында фикер алышына;

эксперт комиссиясе җитәкчесе эксперт комиссиясенең эш нәтиҗәләре һәм бәяләмә проектының йомгаклары турында җиткерә;

бәяләмә проекты эксперт комиссиясе җитәкчесе, аның җаваплы сәркатибе һәм аның барлык әгъзалары тарафыннан имзалана;

эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм әгъзалары (Министрлыкның штатлы хезмәткәрләреннән тыш) башкарылган эшләрне кабул итү актларына кул куя.

Эксперт комиссиясенең аның җитәкчесе һәм җаваплы сәркатибе, эксперт комиссиясенең исемлек составындагы квалификацияле күпчелеге (кимендә өчтән ике өлеше) тарафыннан әзерләнгән җыелма бәяләмәсе проекты хупланганда, бәяләмә проектына эксперт комиссиясе әгъзаларының тулы составында кул куела, шуннан соң ул эксперт комиссиясе әзерләгән бәяләмә була.

Эксперт комиссиясе әзерләгән бәяләмә аңа кул куйган затлар ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый.

Эксперт комиссиясенең аерым әгъзалары эксперт комиссиясе әзерләгән бәяләмә белән ризалашмаганда, алар бәяләмәгә «махсус фикер» тамгасы белән кул куя. Махсус фикер эксперт тарафыннан экспертның бәяләмә нәтиҗәләре белән ризалашмавының сәбәпләрен нигезләүдән һәм экспертизага тапшырылган материалларның техник регламентларга һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарга ярашлы рәвештә билгеләнгән экологик таләпләргә һәм нормаларга җавап бирмәвенең конкрет фактларына күрсәтүдән гыйбарәт булган документ рәвешендә рәсмиләштерелә.

Эксперт комиссиясе әзерләгән уңай бәяләмәдә түбәндәге нәтиҗәләр булырга тиеш:

дәүләт экология экспертизасы объектын тормышка ашыруга бәйле рәвештә булачак хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне нигезләүче документларның һәм (яки) документациянең техник регламентларда һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән экологик таләпләргә җавап бирүе турында;

экспертиза объектын тормышка ашыру ихтималлыгы турында.

Эксперт комиссиясе әзерләгән тискәре бәяләмәдә ике төрле нәтиҗә булырга мөмкин:

а) эксперт комиссиясе әзерләгән бәяләмәдә бәян ителгән кисәтүләр һәм тәкъдимнәр буенча тапшырылган документларны эшләп бетерү зарурлыгы турында;

б) ниятләгән эшчәнлекнең экологик куркынычсызлык таләпләре үтәлешен тәэмин итмәвенә бәйле рәвештә экспертиза объектын тормышка ашыруның ярамаганлыгы турында.

Тормышка ашырылуы әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясау ихтималы булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектлары буенча дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсендә күрсәтелгән

хокукый акт проектындагы төп нигезләмәләрнең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына һәм экологик куркынычсызлык таләпләренә җавап бирүе (җавап бирмәве) турында нәтиҗәләр, шулай ук әлеге экспертиза объектын тормышка ашыруның экологик һәм шуңа бәйле башка нәтиҗәләре турында нәтиҗәләр булырга тиеш.

Эксперт комиссиясе әзерләгән ике нөсхәдәге, экспертларның махсус фикерләре булган бәяләмә һәм эксперт комиссиясенең ахыргы утырышының беркетмәсе бәяләмә раслау турында боерык проекты әзерләү өчен Министрлыкның вәкаләтле бүлекчәсенә (бүлегенә) тапшырыла.

Эксперт комиссиясенең исемлек составында өчтән бер өлеше җыелма бәяләмә проектындагы нәтиҗәләр белән ризалашмаган очракта, комиссия җитәкчесе Бүлек башлыгы һәм Идарә башлыгы белән берлектә Министрның беренче урынбасарына һәм Министрга тиешле составта комиссия тарафыннан карар кабул итүнең мөмкин булмавы һәм дәүләт экспертизасын уздыру срогын озынайту һәм комиссия составына өстәмә экспертларны кертү турында җиткерә. Дәүләт экспертизасын уздыру срогын озынайту зарурлыгы һәм комиссия составына өстәмә экспертларны кертү турында карар Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Дәүләт экология экспертизасының эксперт комиссиясе бәяләмәсе имзаланганнан соң, җаваплы сәркатип 3 эш көне эчендә эксперт комиссиясе һәм әгъзалары тарафыннан түләүле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән шартнамәләрне һәм эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм әгъзалары тарафыннан башкарылган эшләрне кабул итү актларын күрсәтелгән эшләргә (хезмәтләргә) түләү өчен Министрлыкның финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлегенә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Министрлык боерыгында билгеләнгән, әлеге Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән срок эчендә гамәлгә ашырыла, ул ике айдан артыграк була алмый һәм заказчы гаризасы нигезендә бер айга озынайтылырга мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт экология экспертизасының эксперт комиссиясенең дәүләт экология экспертизасы бүлегенә тапшырылган җыелма (уңай яки тискәре) бәяләмәсе.

3.6.2. Җаваплы сәркатип, 2.9 п. 5 пунктчасы буенча нигезләр булганда, әлеге Регламентның 3.4.3-3.4.4 п. билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра.

3.7. Дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен раслау турында боерык әзерләү һәм чыгару.

3.7.1. 3.6.1 п. билгеләнгән процедура нәтиҗәләре буенча җаваплы сәркатип тарафыннан эксперт комиссиясе әзерләгән бәяләмәне раслау турында боерык проекты әзерләнә һәм эзлекле/параллель рәвештә килештерү һәм раслау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура 3.6.1 п. процедурасы тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эзлекле/параллель рәвештә килештерүгә өчен Бүлек башлыгына, Идарә башлыгына, хокукый тәэминат бүлеге башлыгына, финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгына, Министрның беренче урынбасарына һәм раслау өчен Министрга җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.7.2. Бүлек башлыгы, Идарә башлыгы, хокукый тәэминат бүлеге башлыгы, финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы, Министрның беренче урынбасары, Министр Министрлык боерыгы проектын раслый.

Эксперт комиссиясе әзерләгән бәяләмә Министрлык боерыгы белән расланганнан соң дәүләт экспертизасы тәгәлләнгән булып санала.

Эксперт комиссиясе әзерләгән бәяләмә аны раслаган көннән башлап дәүләт экспертизасы бәяләмәсе статусына ия була.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.7.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган Министрлык боерыгы.

3.8. Расланган дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен бирү.

3.8.1. 3.7 п. билгеләнгән процедура нәтиҗәләре буенча җаваплы сәркатип түбәндәгеләр адресына хәбәр проектлары әзерли:

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт экология экспертизасының тәгәлләнүе һәм дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе җибәрелүе турында;

Министрлыкның территориаль идарәләре;

җирле үзидарә органнары һәм экологик экспертиза өлкәсендәге федераль башкарма хакимият органы билгеләгән очракларда;

дәүләт экспертизасы объектының тормышка ашырылуын финанслаучы кредит оешмалары.

Министрлыкның дәүләт экология экспертизасы бүлеге «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат, дәүләт экспертизасын уздыру нәтиҗәләре турында хәбәр урнаштыра.

Дәүләт экспертизасына тапшырылган документларның бер нөсхәсе, ул тәгәлләнгәннән соң, Министрлык архивында саклау өчен формалаштырыла, калган документлар мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелә. Документларны архивта саклау срогы итеп әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнарны бозу нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турында дәгъва белдерү срогы билгеләнә һәм егерме ел тәшкил итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура 3.7 п. күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына, Идарә башлыгына, Министрның беренче урынбасарына, Министрга эзлекле/параллель рәвештә килештерү һәм кул кую өчен җибәрелгән Министрлыктан хәбәрләр проектлары.

3.8.2. Бүлек башлыгы, Идарә башлыгы, Министрның беренче урынбасары, Министр хәбәрләрнең проектларын килештерә/имзалый.

Министр, алар башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә, дәүләт корпорацияләре һәм холдинглары җитәкчеләренә җибәрелгән очракта, хәбәрләргә кул куя. Бүтән очракларда хәбәргә Министрның беренче урынбасары кул куя.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.8.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган Министрлык хәбәрләре.

3.9. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны аша күрсәтү тәртибе.

Дәүләт хезмәте күрсәтү күпфункцияле үзәктә һәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

3.10. Техник хаталарны (язу, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.10.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза (2 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган документ;

техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкиле)тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә), яисә Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә.

3.10.2. Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша электрон рәвештә терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза.

3.10.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның чын нөсхәсен алып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша Министрлыкка техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның чын нөсхәсен тапшырган очракта документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыкланганнан соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хатасы) турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору түбәндәгеләрне үз эченә ала: Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, шикаятьләр карау, тикшерүләр уздыру, Мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

- дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документларның проектларына экспертиза уздыру. Экспертизаның нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;
- эш алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерү;
- билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр Министрлык эшенең ярты еллык һәм еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Планнан тыш тикшерүләр мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча уздырыла.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедуралар башкарылуны тикшереп тору максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. ДӘүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануы буенча агымдагы контрольлек Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Әлеге Регламент үтәлешен тикшерүдә тотучы вазыйфаи затларның исемлеге Министрлык бүлекләре турында нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Күрсәтелгән тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру ешлыгын министр билгели.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Министр (Министрның беренче урынбасары) мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында каралуын тикшерүдә тота.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук вазыйфаи затларның, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерергә хокуклы, судка кадәр тәртиптә, – Министрлыкка. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә министр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә

5.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның дәүләт хезмәткәренең, җитәкчесенең карарларына, гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://gosuslugi.ru), күпфункцияле үзәк аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (оешманың), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

ГАРИЗАНЫҢ КИҢӘШ ИТЕЛӘ ТОРГАН ФОРМАСЫ

Дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү өчен җибәрәбез:

______________________________________________________________________________

(дәүләт экология экспертизасы объектының аталышы)

Кушымта:

- дәүләт экология экспертизасына тапшырыла торган материалларның тәфсилле исемлеге биттә, нөсхәдә;

- дәүләт экология экспертизасы уздырганда мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү өчен счет әзерләү өчен кирәкле реквизилар (ИНН, БИК, КПП, ОКПО, исәп-хисап счеты, к/счет)

Гаризада һәм теркәлә торган документларда тапшырылган мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын раслыйм.

Җитәкче ___________________________ ____________ _____________

(оешманың аталышы) (имза) (Ф.И.А.)

М.У. (булган очракта)

__________________

(дата)

Элемтә өчен телефон/факс/E-mail:__________________________________

Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына

______________________________________________

Кемнән: ____________________________________

(физик затлар, шәхси эшкуарлар өчен: Ф.И.А.,адресы (почта һәм (яисә) электрон)

________________________________________

юридик затлар өчен: оешманың аталышы, адресы (почта һәм (яисә) электрон)

Техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата (язу, басма хаталары, грамматик яисә арифметик хаталар) турында хәбәр итәм

_____________________________________________________________________________

(хезмәтнең аталышы)

Язылган: _________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Дөрес белешмәләр: ____________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

e-mail:_________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

_________________________________________________________________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә(яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, ябуга, юкка чыгаруга, шулай

ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның ризалыгын раслыйм.

Хәзергесе белән шунысын раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкил булган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.


Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча түбәндәге телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _____________.


____________________ _______________ (______________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.).

Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема




Эксперт комиссиясе составы, ДЭЭ уздыру сроклары һәм эксперт комиссиясе йөкләмәсе Министрлык боерыгы белән раслана
Бүлек җитәкчесе җаваплы сәркатипне билгели
Эксперт комиссиясе утырышлары уздырыла, кирәк булганда анда мөрәҗәгать итүче дә чакырыла
Өстәмә экспертларны кертү Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә
ДЭЭ уздыру срогын озынайту таләп ителә
ДЭЭ уздыру срогын озынайту Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә
Өстәмә материаллар тапшыру таләп ителә
Җаваплы сәркатип мөрәҗәгать итүчегә өстәмә материаллар тапшыру зарурлыгы турында хәбәр җибәрә
Мөрәҗәгать итүче кирәкле материалларны тапшыра
Өстәмә экспертларны җәлеп итү таләп ителә
Эксперт комиссиясе җитәкчесе ДЭЭ җыелма бәяләмәсе проектын әзерләүне оештыра
Мөрәҗәгать итүчене, иҗтимагый оешмаларның вәкилләрен (зарурлык булганда) чакырып, ахыргы утырыш уздырыла
Бәяләмә эксперт комиссиясе әгъзаларының тулы составында имзаланган
Җаваплы башкаручы сметаны һәм түләү счетын өстәмә экспертларны кертүгә түләү кирәклеге турында хәбәр итеп җибәрә
ДЭЭ бәяләмәсе Министрлык боерыгы белән раслана
Счет түләнгән (түләү йөкләмәсенең күчермәсе тапшырылган)
ДЭЭ бәяләмәсе мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә
Өстәмә экспертларны кертү һәм срокны озынайту Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә
ДЭЭ бәяләмәсе турында мәгълүмат Министрлыкның территориаль органнарына һәм җирле үзидарә органнарына, экологик экспертиза өлкәсендә федераль башкарма хакимият билгеләгән очракларда, ДЭЭ объектын тормышка ашыруны финанслаучы кредит оешмаларына җибәрелә
Мөрәҗәгать итүчене, иҗтимагый оешмаларның вәкилләрен (зарурлык булганда) чакыртып, ахыргы утырыш уздырыла
Уңай бәяләмә
Объектны тормышка ашыру
Объектны тормышка ашыруны тыю

Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына белешмәлек кушымта

Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизаын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнарның һәм вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр – Шадриков Александр Валерьевич | 267-68-01 | Aleksandr.Shadrikov@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары – Камалов Рөстәм Илдар улы | 267-68-90 | Rustem.Kamalovl@tatar.ru |
| Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу идарәсе башлыгы – Шәһидуллина Рәисә Габдулла кызы | 267-68-90 | Raisa.Shagidullina@tatar.ru |
| Дәүләт экология экспертизасы бүлеге башлыгы – Манидичева Ольга Владимировна | 267-68-31 | Olga.Manidicheva@tatar.ru |
| Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге башлыгы – Хәннанова Гөлнара Рәсил кызы | 267-68-04<br>267-68-05 | eco@tatar.ru. |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Җир асты биләмәләреннән, табигать ресурсларынан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы – Фәсхетдинов Марат Гайса улы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |